Сайт школы:
http://kazan33.ru

# ШКОЛА РАДОСТИ

Издается
с 2009 года

№6 (77) 2015

• ГАЗЕТА ШКОЛЫ №33 АВИАСТРОИТЕЛЬНОГО РАЙОНА г. КАЗАНИ •

# Татар теле – туган телем!



**Алия НИЗАМЕЕВА, 11 «Ф»**

*И туган тел, и матур тел,*
*әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем*
*син туган тел аркылы.*
***(Габдулла Тукай)***

Әйе, Тукай бабабыз шушы шигырь юлларында телебезнең матурлыгын, бөеклеген, бабаларыбыз, әти-әниләребез теле – татар теле булуын әйтә. Бу шигырь безнең өчен генә түгел, барчы дөнья халкына да карый, чөнки иң элек, бала дөньяга килгәч, хәтта, корсакта булган чакта ук, анасы белән аралаша. Ана үз телендә бала белән аралаша, сөйләшә башлый һәм бала анасының сүзен аңлый.

«Саф әле күңелең синең, һичбер бозык уй кермәгән, Пакъ телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән», - монысы да Тукай бабай сүзе.

Өйдә ата-ана татарча сөйләшергә, балага да татарча эндәшергә тиеш. Ләкин, шулаймы соң? Юк! Эштән кайталар да, вата-җимерә, русча куша-куша бала белән сөйләшергә тотыналар. Аннан үсә төшкәч, балалар бакчасына бирәләр һәм башлана инде: бала, аптырап кала, анага күзен төбәп тора.

***(дәвамы 2нче биттә)***

## ЧИТАЙТЕ В НОМЕРЕ:

2 бит — ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК - ЦЕННЫЙ ЯЗЫК
3 бит — МИНЕМ ЯРАТКАН ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫМ
4 бит — «МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!» АКЦИЯСЕНДӘ КАТНАШАБЫЗ

## ТУГАН ТЕЛЕМ - **ИРКӘ ГӘЛЕМ!**

**Рамилә ХӘКИМОВА, 5 «А»**

Һәр кешенең үзенең туган теле бар. Минем туган телем – татар теле. Бу бик матур, бай тел. Мин татар телендә сөйләшеп үстем.

Хәзер миңа унбер яшь һәм мин татар телендә сөйләшеп, татар телен яратып яшим. Минем гаиләм татар телен яхшы белә. Өйдә без гел татар телендә сөйләшәбез. Туган телемне мин бик яратам! Мин татар телен ишетеп тудым, татар телендә сөйләшеп бик матур гына яшим.

## КЫСКАЧА ЯҢАЛЫКЛАР

■ 16нчы февральдә мәктәптә **татар теле һәм әдәбияты айлыгы** башланды. Аның кысаларында сыйныфтан тыш чаралар, викториналар һәм татар теленнән ачык дәресләр үтте.

■ 16нчы февраль көне Советлар Союзы Герое, шагыйрь *Муса Җәлилгә* багышланды. Мәктәп радиосыннан аның шигырьләренә язылган җырлар яңгырады. Актлар залында укучылар өчен «Моабит дәфтәрләре» фильмы күрсәтелде.

■ 24нче февральдә *«Туган телем – татар теле, туган җирем – Татарстан»* дигән әдәби-музыкаль кичә үтте. Кичәбез Халыкара туган тел көненә багышланган иде.



■ 25нче февраль көнне 1нче һәм 2нче сыйныф укучылары укытучылары Хөснетдинова А.Ә. һәм Фәйзелгатова Ч.Х. белән бергә *«Яраткан туган телебез, яраткан туган җиребез»* дигән кичә тәкъдим иттеләр. Яшь артистларның чыгышлары бөтен кешегә дә бик охшады. Афәрин!

**Хәбәрләрне Инзилә ШАКИРОВА әзерләде**

# ТАТАР ТЕЛЕ – **ТУГАН ТЕЛЕМ!**

*(башы 1нче биттә)*

Татарча сөйләшмәгәнгә күрә, инде сүзләрен дә оныта башлый, татарча җавап бирә алмый. Инде мәктәпкә баргач, русча гына сөйләшәләр, инглизчә гына укыйлар, әмма иптәшләре янында татарча сөйләшергә оялалар. Менә бу инде зур югалту дигән сүз. Күпме генә татарча эндәшсәң дә, бала аңламый, телен югалта бара. «Агачка яшьтән су сип», - дигән элекке бабаларыбыз. Яшьтән өйдә ата-аналар бала белән татарча гына сөйләшсә икән, ул аны онытмаячак. Бик кызганыч, ләкин ата-аналар үзләре балаларын телсез, гореф-гадәтсез үстерәләр. Янәсе: «Нәрсәгә ул татар теле, беркем дә сөйләшми, ник кирәк ул балага?» - диләр. Ата-ана ни чәчсә, шуны урачак! Телсез һәм моңсыз үсәләр шул балалар...



Мин болай дип әйтер идем: «Ата-ана булуны истә тотыгыз, шул исемгә лаек булыгыз! Балагыз бервакыт та үз телен онытмасын, оялмасын! Балага карата игътибарлы булыгыз». Балагыз: «Минем телем – татар теле!» - дип горурланырлык булсын. Шулай итеп кенә, татар телебезне өйрәнеп, сөйләшеп кенә, без үзебезнең бөек милләтебезне саклап кала алырбыз! Онытмагыз шуны, кадерле милләтәшләрем! Әйдәгез, саф татар телебездә сөйләшик!

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК – **ЦЕННЫЙ ЯЗЫК**

**Кристина ПЕТРЕНКО, 8 «Б»**

Татарский язык – это особо интересный язык народов мира. Я начала изучать этот язык впервые в 13 лет, так как переехала жить в Татарстан. Я слышала много различных языков, но татарский язык зацепил мою душу. Этот язык очень интересен своим произношением. У меня замечательный учитель татарского языка – *Хуснутдинова Хамзия Хамбеловна.* Она всегда доступно объясняет нам новые темы. Мне было очень сложно начинать изучать совершенно новый для меня язык, но благодаря хорошему учителю у меня все получается. Мне интересно каждый урок узнавать что-то новое об этом языке.

Многие люди задаются вопросом: «Для чего нам нужен татарский язык?» Я могу ответить так: татарский язык мы изучаем для того, чтобы быть вместе с республикой Татарстан. Этот язык связывает народ и города. Так же благодаря татарскому языку мы можем общаться во многих других странах. В общем, татарский язык нам нужен, ведь это очень ценный язык, который переходит из поколения в поколение и его нужно изучать и уважать!

# МИНЕМ ЯРАТКАН **ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫМ**

**Айсылу ГАТАУЛЛИНА, 4 «В»**

Минем татар теле укытучым – *Хөснетдинова Хәмзия Хамбәл кызы.* Безнең татар төркеме кечкенә, унике кеше генә, ләкин безнең дәресләр бик күңелле үтә. Хәмзия Хамбәл кызы безгә төрле эшләр бирә. Без проектлар эшлибез, конкурсларда катнашабыз.




Хәмзия Хамбәл кызы – бик яхшы кеше. Аның теләге – безне акыллы һәм тәртипле балалар итеп күрү. Ул үзе бик матур: кыска коңгырт чәчле, соргылт күзле. Аның холкы да яхшы: ул безгә кычкырмый, кызыксындырырга тырыша. Ул бездә яхшы кешеләрне күрә, а без аны аңламыйбыз. Кайвакыт без шаярабыз, ләкин Хәмзия Хамбәл кызы хәйләкәр. Ул безгә шунда ук: «Дәфтәр битләре алыгыз, хәзер сүзлек диктанты язабыз», - ди. Шулай да мин татар теле укытучымны бик яратам!



**Рамилә ХӘКИМОВА, 5 «А»**

Татар теле – нәрсә ул? Бу безнең туган телебез, ләкин аны яхшырак белер өчен, аны өйрәнергә кирәк. Татар телен безгә безнең яраткан татар теле укытучылары укыта. Минем укытучым иң яхшысы! Аның исеме – *Гыйниатуллина Гөлия Шәйнуровна*. Ул татар телен әйбәт укыта һәм мин аны бик яратам. Ул матур, игелекле, бер сүз белән әйтсәң, ул – иң яхшы укытучы.

Гөлия Шәйнуровна белән дәресләребез дә кызык үтә. Без татар телендә сөйләшәбез, төрле күнегүләр ясыйбыз, сыйныфташларыбыз белән диалоглар төзибез. Мөстәкыйль эшләр дә еш үтә. Мин алардан бишлеләр генә алырга тырышам. Мин татар телен рәхәтләнеп өйрәнәм! Һәм Гөлия Шәйнуровнага бөтенесе өчен дә рәхмәт әйтәм!



**Дамир ГАНИЕВ, 7 «В»**

Минем татар теле укытучым – *Ахметшина Резедә Мәсхүт кызы.* Ул укытучы бик тыныч, сабыр һәм ягымлы. Дәрестә ул темаларны бик әйбәт аңлата. Аны укучылар хөрмәт итә. Резедә Мәсхүтовна балаларны бик ярата. Ул безне саф татар телебезгә өйрәтә. Мин үзем дә татар телен өйрәнүне иң беренче урынга куям. Бу телне өйрәнү бик авыр. Бу бик тә җаваплы эш, Татарстанда бик кирәкле дәрес. Хәтта кырыкилле яшьлек кешеләр дә, татар телен өйрәнергә тырышалар. Аның дәресләрендә бик кызык. Мин үземнең мондый татар теле укытучым булганым белән бик горурланам!



**4 «А» сыйныф укучылары**

Безнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы – *Хәбибуллина Фәридә Фоат кызы*. Без аны бик яратабыз. Безнең группада 17 укучы. Без барыбыз да «4» һәм «5»ләргә укыйбыз. Дәресләрдә без хикәяләр укыйбыз, контроль эшләр эшлибез, сорауларга җавап бирәбез, шигырьләр, җырлар өйрәнәбез, төрле ярышлар уздырабыз, диалоглар төзибез, төшеп калган репликаларны язабыз. Әле тагын без группаларда төрле эшләр эшлибез, ачык дәресләр күрсәтәбез. Татар әдәбияты дәресләрендә без язучылар белән танышабыз, бик күп яңалыклар беләбез. Безнең укытучыбыз супер! Без татар теле дәресләренә яратып йөрибез!



***P.S.*** *Безнең мәктәптә иң яхшы татар теле укытучылары эшли. Алар барысы да үз эшләренең осталары. Татар телебезгә мәхәббәт тәрбияләүләр. Рәхмәт аларга!*

## БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ!

■ Мәктәптә **татар теле һәм әдәбияты айлыгы** кысаларында үткәрелгән иншалар конкурсында *«Минем туган телем»* номинациясендә җиңүчеләр: **I** урын – **Низамеева Алия (11 Ф),**
**II** урын – **Шәнгәрәев Илнар (11 Ф).**

■ *«Минем татар теле укытучым»* номинациясендә җиңүчеләр:
**I** урын – **Гатауллина Айсылу (4 В),**
**II** урын – **Хакимова Рамилә (5 А),**
**III** урын – **Ганиев Дамир (7 В)**

■ *«Татар телен белү нигә кирәк?»* номинациясендә рус телендә иҗат ителгән эшләр арасында **I** урынга **Петренко Кристина (8 Б)** лаек дип табылды.

■ *«Безнең татар теле дәресләре»* номинациясендә җиңүчеләр:
**I** урын – **Гатауллина Алия (4 В),**
**II** урын – **4 А сыйныф** укучылары.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**



# «МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!»

**Адилә ШӘЯХМИТОВА, Лия ӘМИНОВА, 5 «А»**

Яз айлары Казанның 33нче номерлы мәктәбендә яңалык белән башланып китте. Быел без бөтен мәктәп белән «Мин татарча сөйләшәм!» республика акциясендә катнашырга булдык.



Акция татар теле айлыгы кысаларында булып узды. «Туган телем – татар теле, туган җирем – Татарстан» әдәби-музыкаль кичә белән башланып китте. Ике атна дәвамында мәктәптә төрле кызыклы чаралар үткәрелде. Башлангыч сыйныфлар класс сәгатьләрендә татарча шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар. Рус төркемнәрендә укучы бишенче сыйныф укучылары «Яз килә» темасына проектлар башкардылар. Аларны матур итеп татар телендә якладылар.

Урта сыйныф укучылары татар теле буенча викторинада катнаштылар. Ә каләм тибрәтүчеләр «Минем туган телем», «Безнең татар теле дәресләре», «Минем татар теле укытучым», «Татар телен белү нигә кирәк?» темаларына иншалар яздылар.

Һәр көнне мәктәп радиосыннан татарча җырлар яңгырады. Шулай ук төрле темаларга укучылардан интервью алынды. Ә мәктәп китапханәсендә татарча китаплар күргәзмәсе оештырылды.

Иң кызыклы эш исә безнең сыйныфка эләкте! Без татар теле укытучылары Ләйсән Фәнис кызы Фәйзуллина һәм Гөлия Шәйнур кызы Гыйниатуллина белән сүзлек-буклет төзедек һәм Авиатөзелеш районы буенча лингвистик сәяхәткә чыктык. Кибет, дарухanә, хастаханә, чәчтарашханә, кафе, автобус тукталышларында булып, районыбыз халкын акция белән таныштырдык. Татарча сөйләшә белүчеләр белән рәхәтләнеп татарча сөйләштек. Рус кешеләренә исә буклетларны тараттык. Кешеләр безне бераз гаҗәпсенеп һәм шул ук вакытта кызыксынып кабул иттеләр. Безгә үзебезгә әлеге акциядә катнашу бик ошады. «Без татарча сөйләшәбез!» – дип горурланып әйтә алабыз!



ШКОЛА РАДОСТИ
**Главный редактор:** Файзуллина Л. Ф.
**Дизайн и верстка:** Файзуллина Л.Ф.
**E-mail:** kazan-school33@yandex.ru
**Сайт школы:** http://kazan33.ru
Тираж 100 экз.
**Адрес редакции:** 420037, РТ, Казань, ул. Симонова, д. 17, ПРЕСС-ЦЕНТР
**Телефон школы:** (843) 510-78-10
**Телефон редакции:** 8 (917) 247-60-30